# Программа дополнительного образования для детей 6-7 лет «Уйныйбыз да җырлыйбыз»

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы**
**№9 балалар бакчасы тәрбиячесе Хисматуллина Р.Р. төзегән**
**“Уйныйбыз да җырлыйбыз” дип исемләнгән түгәрәк эше**
**программасына**
**рецензия**

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән түгәрәк эше алып бару, балаларның максатчан рәвештә сөйләмен үстерү, әдәби әсәрләргә кызыксыну уяту, халык авыз иҗаты аша зәвыклык тәрбияләү һәм үстерү, ана телендә әхлак, милли тәрбия алып бару, кечкенә яшьтән балаларның милли үзаңын үстерү әһәмиятле проблемаларның берсе. Әхлак, эстетик тәрбиясе нигезләре мәктәпкәчә чорда салына һәм алар күпчелек очракта баланың коммуникатив һәм социомәдәни үсешен билгели. Бу аспектлардан караганда түгәрәк эше программасының эшләнүе аеруча зарури. Җырлы, биюле уеннар аша балалар туган телне, аралашу кагыйдәләрен өйрәнәләр, халкыбызның милли гореф-гадәтләре, йолалары белән танышалар, сәнгатькә кызыксыну барлыкка килә, иҗади сәләтләре үсә.

“Уйныйбыз да җырлыйбыз” дип исемләнгән түгәрәк эше программасының билгеле бер структурасы бар. Аңлатма язуында актуальлелек ачыклана, максат һәм бурычлар бәян ителә, көтелгән нәтиҗәләр күрсәтелә. Эчтәлек балалар белән үткәрелә торган төрле төрдәге уеннарны үз эченә ала. Балалар белән үткәрелә торган уеннар тематик план рәвешендә таблицада бирелә. Тематик планда 6-7 яшьтәге балаларга тәкъдим ителгән әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар, хәрәкәтле уеннар, драматизация уеннары, бармак һ.б.уеннар күрсәтелә. Бу уеннар эчтәлеге буенча кызыклы. мавыктыргыч, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып сайланган. Уеннарны үткәрүнең методикасы күрсәтелгән. Автор уеннар белән җитәкчелек иткәндә, балаларның танып белү сферасына, сөйләм үстерүгә һәм әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә аеруча игътибар бирә. Кушымтада төрле уеннарның эчтәлеге тәкъдим ителә.

№9 балалар бакчасы тәрбиячесе Хисматуллина Р.Р. төзегән “Уйныйбыз да җырлыйбыз” дип исемләнгән түгәрәк эше программасы мәктәпкәчә учреждениеләрендә эшләүче педагоглар, тәрбиячеләр, өстәмә белем бирү педагоглары, практика үтүче студентлар өчен гамәли яктан әһәмиятле. Куллануга тәкъдим ителә.

Рецензент:
Яр Чаллы педагогика университеты,
педагогик фәннәр кандидаты,
З.Т. Шәрәфетдинов ис.
педагогика һәм психология
кафедрасы доценты

И.Җ. Хәбибуллина

17. 02. 2021 ел

Отдел делопроизводства и канцелярии
ИНН 1660017589

Подпись Хәбибуллина
ЗАВЕРЯЮ
Начальник канцелярии
Дата 17 февраля 2021

## Аңлатма язуы

Әлеге программа түбәндәге норматив документларга нигезләнеп эшләнде:

Бала хокуклары турында Конвенция 13.06.1990 №1559-1;

РФ Конститутциясе 12.12.1993. Россия Федерациясе Законнары һәм РФ Конституциясенә төзәтмәләр кертүне исәпкә алып 30.12.2008 №6-ФКЗ һәм 30.02.2008;

29.12.2012ел №273-ФЗ “Россия Федерациясендә Мәгариф турында Федераль закон;

“Татарстан Республикасында татар телен дәүләт теле буларак файдалану” законы 12.01.2013 №1-ЗТР;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән Министрлыгы боерыгы 29 август 2013ел №1008 “Белем бирү эшчәнлеге буенча өстәмә гомумбелем бирү программаларын оештыру һәм гамәлгә ашыру” тәртибен раслау турында;

Мәктәпкәчә оешмаларда эш режимы төзү, тоту һәм оештыру өчен санитария-эпидемиология таләпләре” 1.2.3685-21 №2нче 28.01.2021ел;

РФ Мәгариф һәм фән министрыгы боерыгы белән расланган мәктәпкәчә Федераль дәүләт белем бирү стандарты 17.11.2013ел;

“Федераль мәктәпкәчә белеем бирү программасы”, РФ мәгариф министрлыгы тарафыннан №1028 приказы белән расланды;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәре 9нчы балалар бакчасы муниципаль системасындагы мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең уставы

Мәктәпкәчә яшь ул – баланың көчле үсү һәм камилләшү, беренчел белемнәр алу чоры. Бу чор – баланың шәхес буларак тәрбияләнүенә беренче адымнар салынган җаваплы чор.
Зөхрә Салихова хәрәкәтле һәм җырлы уеннар аша балаларга тулы һәм дөрес тәрбия бирергә мөмкин дип саный. Ул балаларның алдагы тормышында танышачак күп нәрсәләрне уен белән күңелләренә сеңдерү мөмкинлегенә басым ясый.

Ул баланың эчке дөньясын күзаллаулар һәм һәртөрле төшенчәләр белән баетып торган якты тәрәзә. Уен ярдәмендә бала көчле, тырыш, сәләтле, нык ихтиярлы булып үсә.

Уеннар күптөрле: хәрәкәтле, сюжетлы- рольле, музыкаль, үстерешле танып белү уеннары һ.б.

Уеннар балаларның төрле яктан үсүен тәэмин итә. Хыялларын баетуда, фикер активлыгы үстерүдә ныклы этәргеч булып тора.

Уеннар, үткәрелү *максатыннан* чыгып, өч аспектка нигезләнә:

1. *Танып белү.* Балаларның иҗади күзаллауларын арттыру, логик фикерләү сәләтен үстерү.
2. *Сөйләм үстерү.* Балаларның диалогик сөйләмен формалаштыру, сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм күнекмәләре бирү.
3. *Әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.* Уеннар ярдәмендә балаларда дуслык, иптәшлек, гаделлек тәрбияләү; эшләгән эшенә бәя бирергә өйрәтү; игътибарлык кебек матур сыйфатлар тәрбияләү.

Балалар белән эшчәнлек вакытында уеннарны сайлый белү зур әһәмияткә ия. Тәрбияче балаларның шәхси мөмкинлекләрен, уен белән ни дәрәҗәдә кызыксынуларын һәрвакыт истә тотарга тиеш.

Һәр тәрбиячедән уеннарны җанлы, кызыклы, тәэсирле итеп оештыра белү сорала. Һәрбер уен түбәндәге схема буенча сүрәтләнә:

1. *Уенның эчтәлеген аңлату.* Балалар җыелып беткәч, тәрбияче уенның исемен әйтә, эчтәлеген сөйли.
2. *Уенның кагыйдәләре белән таныштыру.* Кагыйдәләрне үтәү зур тәрбияви әһәмияткә ия.
3. *Уен барышы.* Уен барышында тәрбияче барлык балаларга да игътибарлы булып, аларны күзәтеп тора, кирәк чакта ярдәм итә.

Балалар бакчасы тәрбиячесе өчен уен- балаларны яхшырак аңлау, аларга тагын да ныграк якынаю чарасыда. Чөнки уен вакытында тәрбияче һәр баланың нәрсәгә сәләтле булуын, холкын, гадәтләрен күбрәк аңлый.

Гомумән алганда, бакчада уеннар балаларның шәхси мөмкинлекләрен ача, кәефен күтәрә, күп белергә омтылышны тәрбияли.

**Түгәрәкнең максаты:**

Балаларга үз халкының милли һәм рухи байлыкларын өйрәтү; киләчәктә татарларның бәйрәмнәрен, җырларын, уеннарын торгызуга күпмедер нигез, таяныч булырлык белемнәрне биреп калдыру; тотырыклы шәхес тәрбияләү.

**Түгәрәкнең бурычлары:**

1.Балаларга татар халык уеннарын өйрәтү.

2. Сөйләм телен үстерү, коммуникатив дәрәҗәсен күтәрү, социальләштерү.

3. Балаларда халык авыз иҗаты, шигырләр, җырлар , уеннар аша тәвәкәллек, түземлек, сабырлык кебек сыйфатлар тәрбияләү; киләчәк тормышта үз урыннарын табуга беренче адымнарын ясарга ярдәм итү.

Түгәрәкнең бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур.

**Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:**

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уенда катнашу.
2. Рәсемнәр, битлекләр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар;

4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Аудиоязмалар тыңлау,карау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү
9. Интерактив уеннар.

**Түгәрәкнең принциплары:**

- системалылык;
-белем бирү өлкәләренең интеграциясе;
- балага шәхес буларак якын килү;

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

1.Уеннар аша балаларда татар теленә кызыксыну уяту.
2.Үз телендә матур сөйләшү, йола-бәйрәмнәрен танып-белү.
3. Халык-авыз иҗатын уеннарда, аралашуда мәстәкыйль куллана белү.

Программа балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып , көннең икенче яртысында, атнага 30 минут исәбеннән төзелгән , 32 белем бирү эшчәнлеге.